**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 29 октябрендәге 4563 номерлы карары**

# Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар җитештерүчеләргә, эшләр башкаручыларга, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлауларны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2023 елның 14 декабрендәге 2-27 номерлы «2024 елга, 2025 һәм 2026 елларның план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 1287 номерлы «2020 - 2026 елларга Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү программасы турында»гы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Расларга:

1.1. әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

1.2. әлеге декарарга 2 номерлы кушымта нигезендә Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә гаризаларны сайлап алу комиссиясе (алга таба – Комиссия) турында нигезләмәне;

1.3. әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендә Комиссия составын.

2. Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратын билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 29 октябрендәге
4563 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге тәртип Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 1287 номерлы «2020-2026 елларга Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү программасы турында»гы карары белән расланган 2020-2026 елларга Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү программасы чараларын гамәлгә ашыру максатыннан эшләнде һәм Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү шартларын һәм механизмын (алга таба – тиешенчә куеп, Тәртип, субсидияләр) билгели.

2. Субсидия сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә. Сайлап алуны уздыру ысулы булып тәкъдимнәр (гаризалар) сорату тора.

3. Каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнарның юнәлеше – икенчел чималны җыю һәм эшкәртү эшчәнлегенә бәйле җиһаз сатып алу, икенчел чималны җыю урыннарын (пунктларын) сатып алу һәм (яисә) кору һәм (яисә) җиһазлау.

4. Субсидия түбәндәгечә бирелә:

- икенчел чималны җыю һәм эшкәртү эшчәнлегенә бәйле җиһазлар сатып алу буенча түләүгә субъектның документаль расланган чыгымнарының 50 проценты күләмендә, әмма 2 000 000 (Ике миллион) сумнан артык түгел;

- икенчел чималны җыю урыннарын (пунктларын) сатып алуга һәм (яисә) төзекләндерүгә документаль расланган чыгымнарның 50 проценты күләмендә, әмма 1 000 000 (Бер миллион) сумнан артык түгел.

5. Субсидия бирү Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан Казан шәһәре Думасыны тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы

карарында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм әлеге Тәртиптә күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү өчен билгеләнгән тәртиптә бюджет чараларын алучы буларак Вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

6. Субсидия турындагы мәгълүматлар, бюджет турында закон (карар) (бюджет турындагы законга (划арарга) үзгәрешләр кертү турында закон (карар)) кабул ителгән көннән соң килүче унбиш эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) (бердәм портал бүлегендә) урнаштырыла.

Субсидия алучыларны сайлап алуны уздыру турында мәгълүмат Вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/komitet-ekonomicheskogo-razvitiya/biznes-v-kazani) (алга таба – рәсми сайт) урнаштырыла.

7. Субсидия алу хокукына түбәндәге критерийларга туры килә торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (алга таба – субъектлар) ия:

- эшчәнлекнең төп төре ОК 029-2014 Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы буенча 38 ОКВЭД «Калдыкларны җыю, эшкәртү һәм утильләштерү; икенчел чималны эшкәртү» кодына ия (2007 елның 24 июлендәге №209-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы нигезендә ярдәм күрсәтелми торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан тыш);

- субъект турында мәгълүматлар Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән;

- Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып бара;

8. Субсидия алучы, сайлап алуда катнашучыларның Тәртип белән билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килүеннән, сайлап алуда катнашучы тапшырган документларның Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килүеннән һәм сайлап алуда катнашучыларның сайлап алуда катнашуга гаризалары килеп керешү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (алга таба – сайлап алуда катнашучылар) тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәр (гаризалар) нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

9. Субсидия алучыларны билгеләү максатыннан Вәкаләтле орган, сайлап алуда катнашучыларны сайлап алуда катнашуга гаризалар кабул ителә башлау көненә кадәр кимендә өч эш көненнән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне

күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерүне рәсми сайтта урнаштыруны тәэмин итә:

- сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштыру датасын;

- сайлап алуны уздыру вакытын;

- сайлап алуда катнашучыларны сайлап алуда катнашуга гаризалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасын, шул ук вакытта гаризаларны кабул итү тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән 10 календарь көннән иртәрәк була алмый;

- Вәкаләтле органның атамасын, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын, элемтә телефонын;

- субсидияләр бирү нәтиҗәсен;

- Вәкаләтле орган сайтының домен исемен һәм (яисә) челтәр адресын һәм (яисә) сәхифәләр күрсәткечләрен;

- Тәртипнең 7 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучылар туры килергә тиешле сайлап алу критерийларын, Тәртипнең 11 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән категориягә, критерийларга һәм таләпләргә туры килүен раслау өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган документлар исемлегенә таләпләрне;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү тәртибен һәм Тәртипнең 12 пункты нигезендә гаризаларның формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

- Тәртипнең 13 пункты нигезендә гаризаларны эшләп бетерүгә кире кайтару тәртибен;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризаларны кире алу тәртибен, аларны кире кайтару тәртибен, шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире кайтару өчен нигезләрне, сайлап алуда катнашучылар гаризаларына Тәртипнең 15 пункты нигезендә үзгәрешләр кертү тәртибен;

- Тәртипнең 19 пункты нигезендә сайлап алуда катнашуга гаризаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

- Тәртипнең 14 пункты нигезендә сайлап алуда катнашуга гаризага үзгәрешләр кертү тәртибен;

- гаризаларны кире кагу тәртибен, шулай ук аларны Тәртипнең 20 пункты нигезендә кире кагу нигезләре турындагы мәгълүматны;

- сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидияләр күләмен, субсидияләр күләмен исәпләү тәртибен һәм, Тәртипнең 4, 19 пуунктларын исәпкә алып, субсидияләрне сайлап алу нәтиҗәләре буенча бүлү кагыйдәләрен;

- сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турындагы белдерү нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү (сайлап алуда катнашучыларга консультация бирү) тәртибен, аңлатмалар бирүнең башлану һәм тәмамлану датасын;

- үзләренә карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән сайлап алуда катнашучылар (алга таба – сайлап алуда җиңүчеләр) Тәртипнең 22 пункты нигезендә килешүне имзаларга тиешле вакытны;

- Тәртипнең 23 пункты нигезендә җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (баш тартканнар) дип тану шартларын;

- сайлап алу нәтиҗәләрен чыгару беркетмәсен (сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре турындагы документларны) рәсми сайтта урнаштыру вакытларын (әлеге Тәртипнең 21 пункты нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килүче 10 нчы календарь көннән дә соңга калмыйча).

10. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда сайлап алу үткәрүне юкка чыгару турында карар кабул итә:

- сайлап алуны игълан иткәннән соң, чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре һәм Вәкаләтле органга субсидияләр бирүгә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары тулы күләмдә кимү;

- Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә каршы тора алмаслык хәл барлыкка килү.

Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару очрагы барлыкка килгән көннән алып бер эш көне эчендә Вәкаләтле орган, гамәлдән чыгару сәбәпләрен күрсәтеп, сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турындагы карарны рәсми сайтта урнаштыруны тәэмин итә. Тиешле белдерү урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

11. Комиссия утырышы датасына сайлап алуда катнашучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- сайлап алуда катнашучының чит ил юридик заты, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентган арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең

Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда, офшор компанияләренең акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган сатуларда әйләнештә йөри торган гавами акционерлык җәмгыятьләре (шул исәптән халыкара компания статусы булган) капиталында турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук башка Россия юридик затлары капиталында мондый офшор компанияләренең, әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып, турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

- сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки терроризмга катнашлары булу турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- сайлап алуда катнашучы БМО Уставының VII бүлеге, БМО Куркынычсызлык советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында яки БМО Куркынычсызлык советы карарлары нигезендә махсус төзелгән оешмалар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- сайлап алуда катнашучы Тәртип, Казан шәһәренең башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртиптә күрсәтелгән максатларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалар алмый;

- сайлап алуда катнашучы 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

- сайлап алуда катнашучы юридик зат үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булып торучы юридик затка башка юридик затны кушу формасындагы үзгәртеп оештырудан тыш), ябылу процессында түгел, сайлап алуда катнашучыга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучы шәхси эшмәкәр шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган;

- сайлап алуда катнашучы (кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты) тарафыннан чыгымнар 2024 елның 1 июленнән алданрак һәм гариза барлык милек формасындагы оешмалар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр белән икенчел чималны җыю һәм яңадан эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле җиһаз сатып алуга, икенчел чималны җыю урыннарын (пунктларын) сатып алуга һәм (яки) коруга һәм (яки) төзекләндерүгә шартнамәләр (килешүләр) буенча сайлап алуда

катнашу өчен гариза Вәкаләтле органга килеп ирешкән көннән соңга калмыйча башкарылган;

- субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

- дисквалификацияләнгән затлар реестрында юридик зат булып торган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яисә баш бухгалтеры (булган очракта) турында, шәхси эшмәкәр турында һәм субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булган товар җитештерүче, эш башкаручы, хезмәт күрсәтүче физик зат турында белешмәләр юк.

12. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар Вәкаләтле органга сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән вакытта түбәндәгеләрне үз эченә алган сайлап алуда катнашуга гариза тапшыралар:

1) сайлап алуда катнашучының икенчел чималны җыю һәм яңадан эшкәртү эшчәнлеге белән бәйле җиһаз сатып алуга фактта тотылган чыгымнарын раслаучы документлар (шартнамәләр, башкарылган эшләр/хезмәт күрсәтүләр актлары, түләүгә счетлар, түләү йөкләмәләре, контроль-касса техникасы чеклары һәм һәм башка раслаучы документлар) күчермәләрен теркәп, Тәртипкә 1 номерлы кушымта нигезендәге форма буенча сайлап алуда катнашуга гариза;

2) Тәртипкә 2 номерлы кушымта нигезендә субъект турында мәгълүмат;

3) икенчел чималны җыю һәм яңадан эшкәртү эшчәнлеге белән бәйле җиһаз сатып алуга, икенчел чималны җыю урыннарын (пунктларын) сатып алуга һәм (яисә) төзүгә һәм (яисә) төзекләндерүгә субсидияләр күләмен Тәртипкә 3 номерлы кушымта нигезендәге форма буенча исәпләү;

4) Тәртипнең 4 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

5) Федераль салым хезмәте әмере белән билгеләнгән форма буенча салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычын түләү турындагы белешмә.

Юридик зат әлеге пунктта күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) гамәлгә кую документларының һәм аларга кертелгән барлык үзгәрешләрнең юридик зат җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган күчермәләре;

б) җитәкченең вәкаләтләрен раслый торган, юридик зат җитәкчесенең имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган документлар.

Шәхси эшмәкәр тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә шәхси эшмәкәр паспортының күчермәсе (беренче янәшә битләр һәм яшәү урыны буенча теркәлү тамгасы булган янәшә битләр) тапшырыла. Ул шәхси эшмәкәр имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныклана.

Бер субъект субсидия алуга бер гариза бирә ала. Гаризага кертелгән барлык документлар да төгәл бастырылган һәм барлык пунктлар буенча тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела). Чистарту һәм төзәтүләр булырга тиеш түгел. Гаризаның барлык битләренә номер куелган булырга, имза һәм субъектның мөһере (әгәр булса) белән таныкланырга тиеш. Документлар күчермәләре һәм аларның төп нөсхәләре күрсәтелә.

Чит телдәге документларны гариза бирүче аларның федераль законнар нигезендә таныкланган рус теленә тәрҗемәсе белән бергә тапшыра.

Гариза һәм аңа теркәлеп бирелә торган документлар, һәр теркәлгән документ буенча исемлек һәм битләр санын күрсәтеп, юридик зат җитәкчесе яисә шәхси эшмәкәр тарафыннан яки вәкаләтләрен раслаучы һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамәсе булган очракта, аларның вәкаләтле вәкиле тарафыннан кәгазьдә һәм электрон рәвештә (CD, флеш-туплагыч) (һәр документ аерым файл рәвешендә) Вәкаләтле органга кулдан тапшырыла. Ышанычнамәгә сайлап алуда катнашучы исеменнән гамәлләр кылуга Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән сайлап алуда катнашучының вәкаләтле вәкиленнән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирелә.

Сайлап алуда катнашучы тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар, бирү датасын һәм вакытын күрсәтеп, факт буенча кергән көнне теркәлә.

13. Гариза дәгъвачыга, гаризаларны карап тикшерү вакыты тәмамланганчыга кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, эшләп бетерү өчен кайтарыла.

Гариза, аны кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, эшләп бетерүгә җибәрелә. Катнашучы гаризаны эшләп бетерергә юлланган көннән соң килүче көн эчендә гаризага үзгәрешләр кертергә һәм аны кабат бирергә хокуклы.

Өстәмә эшләп җибәрелгән гариза яңадан теркәлми һәм гариза бирү датасы булып дәгъвачының беренчел гаризасын имзалау көне санала.

Гаризалар документларда бетерелгән урыннар, өстәмә язулар булган очракта, шулай ук Тәртипнең 12 пунктына туры килмәгән очракта, эшләп бетерүгә җибәрелә.

14. Сайлап алуда катнашуга гаризалар кабул итү тәмамланганчы, сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашуга яңа редакциядә гариза бирү юлы белән сайлап алуда катнашуга үзгәрешләр кертергә хокуклы. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан Вәкаләтле органга элек җибәрелгән сайлап алуда катнашу өчен гариза (алга таба – сайлап алуда катнашуга алдагы гариза) карап тикшерелми.

15. Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә гаризаларны сайлап алу комиссиясе (алга таба – Комиссия) утырышы көненә кадәр сайлап алуда катнашуга гариза сайлап алуда катнашучы тарафыннан почта аша заказлы хат белән җибәрелгән яки кулга тапшырылган язмача гариза (алга таба – гаризаны кире алуга гариза) нигезендә кире алынырга мөмкин. Бу очракта гариза Комиссия утырышында карап тикшерелми.

16. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда сайлауларны узмаган дип тану турында карар кабул итә:

- гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң, бер гариза да бирелмәгән;

- килеп ирешкән барлык гаризалар сайлап алуда катнашучылар тарафыннан кире алынган.

17. Вәкаләтле орган, сайлап алуда катнашуга гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, тиешле мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән сайлап алучыларга карата түбәндәге документларны һәм мәгълүматны алуны тәэмин итә:

1) Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан (www.nalog.ru) бастырып алына);

2) Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан белешмәләр (Федераль салым хезмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан (www.nalog.ru) бастырып алына);

3) Банкротлык турында мәгълүматларның бердәм федераль реестрында сайлап алуда катнашучы турында мәгълүматлар булу (булмау) турында

мәгълүмат (Банкротлык турында мәгълүматларның бердәм федераль реестрының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан (www.fedresurs.ru) бастырып алына);

4) Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда катнашуга гаризалар кабул итә башлаган айның беренче көненә сайлап алучының Кагыйдәләрдә күрсәтелгән чыгымнарны финанс ягыннан каплау максатларына Казан шәһәренең башка норматив хокукый актлары нигезендә Казан шәһәре бюджетыннан акча алуы (алмавы) турында Казан шәһәре Башкарма комитеты мәгълүматы;

5) экстремистик эшчәнлеккә яисә терроризмга катнашы булулары турында белешмәләре булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә сайлап алуда катнашучы турында белешмәләрнең булуы (булмавы) хакында мәгълүмат (Финанс мониторингы буенча федераль хезмәтнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтының (www.fedsfm.ru) тиешле бүлегеннән бастырып алына);

6) 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агентлары реестрында сайлап алуда катнашучы турында белешмәләрнең булуы (булмавы) турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан (www.minjust.gov.ru) бастырып алына);

7) БМО Уставының VII бүлеге, БМО Куркынычсызлык советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында яки БМО Куркынычсызлык советы карарлары нигезендә махсус төзелгән оешмалар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә сайлап алуда катнашучы турында мәгълүматлар булу (булмау) хакында мәгълүмат (Финанс мониторингы буенча федераль хезмәтнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (www.fedsfm.ru) тиешле бүлегеннән бастырып алына).

18. Вәкаләтле орган, гаризаларны кабул итү тәмамланганнан соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуда катнашучылардан килеп ирешкән гаризаларны, шулай ук сайлап алуда катнашучыларга карата документларны һәм мәгълүматны Комиссиягә җибәрүне тәэмин итә.

19. Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны кабул иткән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Комиссия Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия

алучы сайлап алуда катнашучыларны билгели яки гаризаны кире кагу турында карар кабул итә.

Субсидия бирү, гариза һәм документлар тапшыру датасыннан һәм вакытыннан чыгып, чират тәртибендә башкарыла.

20. Субсидия бирүгә гаризаны кире кагу турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

- хокукый актта каралган сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- конкурста катнашучы тарафыннан хокукый актта каралган тапшырылган гаризаларның һәм (яисә) документларның сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- хокукый акт белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатыннан сайлауда катнашучы тапшырган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

- сайлап алуда катнашучының гариза бирү өчен билгеләнгән көннән һәм (яки) вакыттан соң гариза тапшыруы;

- сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртиптә күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

- әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү өчен Вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән агымдагы финанс елына бюджет йөкләмәләре лимитлары бетү;

- каплау өчен билгеләнгән чыгымнар субъект тарафыннан әлеге Тәртиптә каралмаган максатларга тотылган.

21. Вәкаләтле орган, сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләгән көннән соң килүче ун календарь көннән соңга калмыйча, сайлау нәтиҗәләре турында беркетмәне рәсми сайтка урнаштыра. Анда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

- гаризаларны карап тикшерү датасы һәм урыны;

- гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның сайлап алу уздыру турындагы белдерүнең кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- субсидия алучыларның исемнәре;

- бирелә торгән субсидия күләме.

22. Вәкаләтле орган сайлау нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән алып 10 календарь көн эчендә Казан шәһәре Башкарма комитеты Финанс идарәсенең 2023 елның 12 гыйнварындагы 8 номерлы әмере белән расланган типлаштырылган форма буенча субсидия алучы субъект белән субсидия бирү турында килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

- субсидия бирүнең күләме, максаты, шартлары һәм тәртибе;

- субсидия күчерү вакыты;

- әлеге тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, килешүне (шартнамәне) өзү тәртибе;

- бюджет акчаларын алучы буларак төп бүлүчегә килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү яки, яңа шартлар буенча килештерүгә ирешелмәгәндә, килешүне өзү;

- субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирү тәртибе, вакыты һәм формасы;

- субсидия алучының субсидия бирүче Вәкаләтле орган тарафыннан аңа карата субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен, шул исәптән аны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәлешен тикшерүне, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгы.

Кирәк булганда Вәкаләтле орган субсидия алучылар белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

23. Килешүне билгеләнгән вакытта имзаламаган сайлап алуда җиңүче Вәкаләтле орган карары белән килешү төзүдән баш тарткан дип танылa (карар субсидия алучы тарафыннан килешү имзалау өчен вакыт узганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә).

Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып ике эш көне эчендә килешү төзүдән баш тарткан дип танылган сайлап алуда җиңүченең электрон почтасы адресы буенча, кире кагу сәбәбен күрсәтеп, аңа субсидия бирүне кире кагу турында хәбәрнамә җибәрә.

24. Вәкаләтле орган субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән алып ун эш көне эчендә субсидия алучылар тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк

банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына үзенең шәхси счетыннан акча күчерә.

25. Юридик зат булган субсидияне алучыны кушу, кушылу яки үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп оештырганда, килешүгә, хокуклар күчә торган юридик затны килешүдә күрсәтеп, килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән йөкләмәдә затны алмаштыру өлешендә үзгәрешләр кертелә.

Юридик зат булган субсидия алучыны бүлү, бүлеп чыгару рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы юкка чыгарылганда яисә шәхси эшмәкәр булган субсидия алучының эшчәнлеге туктатылганда, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Казан шәһәре бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны күрсәтеп, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт формалаштырып, килешү өзелә.

26. Субсидия бирү нәтиҗәсе – икенчел чималны җыю һәм эшкәртү эшчәнлегенә бәйле җиһаз сатып алу, икенчел чималны җыю һәм (яисә) җыю урыннарын (пунктларын) сатып алу һәм (яисә) җиһазлау һәм аларны килешү төзегән көннән алып (аны да кертеп) кимендә 12 ай дәвамында эксплуатацияләү.

27. Субсидия алучы кварталга бер тапкыр, үткән кварталдан соң килә торган айның 5 көненнән да соңга калмыйча, субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыра.

28. Россия Федерациясе законнары нигезендә Вәкаләтле орган субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерә, ә дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

29. Вәкаләтле органга субсидияләр алучылар тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучының тиешле вазифаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

30. Субсидия алучы тарафыннан субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартлар үтәлмәгәндә, шул исәптән шартларның үтәлмәве Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерү фактлары буенча ачыкланган очракта, бирелгән субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән алып утыз эш көне эчендә Казан шәһәре бюджеты кеременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

31. Казан шәһәре бюджеты керемено акчаларны үз теләге белән кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

32. Бюджет акчаларыннан файдалануны Вәкаләтле орган контрольдә тота.

---

Тәртипкә 1 номерлы кушымта
(Форма)

Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә гаризаларны сайлап алу комиссиясе рәисенә

______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
(гариза бирүченең иялек килешендә язылган фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
____________________________________________
____________________________________________
(оештыру-хокук формасы)

**Субсидия бирүгә**
**ГАРИЗА**

Казан шәһәре Башкарма комитетының __________________ ________ номерлы карары нигезендә ______________________________________________________________________
______________________________________________________________ тарафыннан тотылган
(оешманың, шәхси эшмәкәрнең тулы исеме күрсәтелә)
һәм икенчел чималны җыю һәм эшкәртү эшчәнлегенә, икенчел чималны җыю урыннарын (пунктларын) сатып алуга һәм (яисә) төзүгә һәм (яисә) төзекләндерүгә бәйле җиһазлар сатып алу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга
(кирәклесенең астына сызарга)
(_______________________________________________________________________________)
субсидия бирүне сорыйм.

Субсидияне түбәндәге реквизитлар буенча күчерүне сорыйм:
банк исеме _______________________________________________________________,
Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры _____________________, төп дәүләт теркәве номеры _______________________, исәпкә кую сәбәбе коды _____________________, банкның тәңгәлләштерү коды __________________, корреспондент счеты ________________________, исәп-хисап счеты номеры _________________________________.

Әлеге гариза белән:
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________:
(оешманың, шәхси эшмәкәрнең тулы исеме күрсәтелә)
түбәндәге критерийларга туры килүен раслыйм:

- эшчәнлекнең төп төре ОК 029-2014 Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы буенча 38 ОКВЭД «Калдыкларны җыю, эшкәртү һәм утильләштерү; икенчел чималны эшкәртү» кодына ия (2007 елның 24 июлендәге №209-ФЗ номерлы федераль

законның 14 статьясы нигезендә ярдәм күрсәтелми торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан тыш);

- Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып бара;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты турында белешмәләр Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән;

- 2024 елның 1 июленнән алып гаризаларны кабул итү тәмамланган көнгә кадәр (аны да кертеп) субъект тарафыннан калдыклар һәм икенчел чимал белән эш итү, аларны сортларга аеру, яңадан эшкәртү белән бәйле җиһаз сатып алу яки эшләп чыгару яисә калдыкларны һәм икенчел чималны җыю, сортларга аеру, яңадан эшкәртү урыннарын төзекләндерү буенча хезмәтләр түләнгән һәм алынган;

- сайлап алуда катнашучы чит ил юридик заты, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда, офшор компанияләренең акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган сатуларда әйләнештә йөри торган гавами акционерлык җәмгыятьләре (шул исәптән халыкара компания статусы булган) капиталында турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук башка Россия юридик затлары капиталында мондый офшор компанияләренең, әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып, турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

- сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки терроризмга катнашлары турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- сайлап алуда катнашучы БМО Уставының VII бүлеге, БМО Куркынычсызлык советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында яки БМО Куркынычсызлык советы карарлары нигезендә махсус төзелгән оешмалар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- сайлап алуда катнашучы Тәртип , Казан шәһәренең башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртиптә күрсәтелгән максатларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалар алмый;

- сайлап алуда катнашучы 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

- сайлап алуда катнашучы юридик зат үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булып торучы юридик затка башка юридик затны кушу формасындагы үзгәртеп оештырудан тыш), ябылу процессында түгел, сайлап алуда катнашучыга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучы шәхси эшмәкәр шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган;

- сайлап алуда катнашучы (кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты) тарафыннан чыгымнар 2024 елның 1 июленнән алданрак һәм гариза барлык милек формасындагы оешмалар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр белән икенчел чималны җыю һәм яңадан эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле җиһаз сатып алуга, икенчел чималны җыю урыннарын (пунктларын) сатып алуга һәм (яки) төзүгә һәм (яки) төзекләндерүгә шартнамәләр (килешүләр) буенча сайлап алуда катнашу өчен гариза Вәкаләтле органга килеп ирешкән көннән соңга калмыйча башкарылган;

- субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре

түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

- дисквалификацияләнгән затлар реестрында юридик зат булып торган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яисә баш бухгалтеры (булган очракта) турында, шәхси эшмәкәр турында һәм субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булган товар җитештерүче, эш башкаручы, хезмәт күрсәтүче физик зат турында белешмәләр юк.

Әлеге гариза белән_______________________________________________________________

_____________________________________________________________________________________

(оешманың, шәхси эшмәкәрнең тулы исеме күрсәтелә)

тапшырылган мәгълүматларның һәм документларның дөреслеген раслый, шулай ук субсидия алу мөмкинлеге бирә торган дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык булуы турында үзенең хәбәрдар булуын раслый.

Әлеге гариза белән_______________________________________________________________

_____________________________________________________________________________________

(оешманың, шәхси эшмәкәрнең тулы исеме күрсәтелә)

Казан шәһәре Башкарма комитетының _____ елның _____________________ ______ номерлы карары белән расланган Казан шәһәре территориясендә теркәлгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү, икенчел чималны җыю урыннарын (пунктларын) сатып алу һәм (яки) төзү һәм (яки) төзекләндерү буенча эшчәнлек белән бәйле җиһаз сатып алу хезмәтләренә түләү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен компенсацияләү өчен субсидияләр бирү тәртибен бозу аны бирү турында карарны гамәлдән чыгару өчен нигез булып торуы хакында хәбәрдар булуын раслый.

Әлеге гариза белән_______________________________________________________________

_____________________________________________________________________________________

(оешманың, шәхси эшмәкәрнең тулы исеме күрсәтелә)

субсидия бирү шартлары турында хәбәрдар булуын раслый.

Гаризага теркәп бирәм:

1. ___ биттә;
2. ___ биттә;
3. ___ биттә;
4. ___ биттә.

Гариза бирү датасы: 20____елның «______» ____________

| | | |
|---|---|---|
| | | / / |
| [вазифа (булган очракта)] | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |

Мөһер урыны

Тәртипкә 2 номерлы кушымта
(Форма)

________________________________________________________турында
(оешманың, шәхси эшмәкәрнең тулы исеме күрсәтелә)

20___елның «_____ » ________________

**МӘГЪЛҮМАТ**

| | |
|---|---|
| Оештыру-хокукый формасын күрсәтеп, субъектның тулы һәм кыскартылган исеме | |
| Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН)/Исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН)/Шәхси эшмәкәрнең төп дәүләт теркәве номеры (ОГРНИП) | |
| Эшчәнлек өлкәсе:<br>- аңлатмасын күрсәтеп, икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторының төп коды<br>- факт буенча башкарыла торган эшчәнлек төрләре | |
| Субъектны дәүләт тарафыннан теркәү датасы һәм органы | |
| Субъектның факт буенча адресы | |
| Элемтә реквизитлары:<br>- телефон;<br>- факс;<br>- сайт;<br>- электрон почта | |
| Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Элемтә өчен зат:<br>- фамилиясе, исеме, атасының исеме;<br>- вазифасы<br>- телефон/факс;<br>- электрон почта | |
| Реквизитлар (банкның тулы исеме, Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры, Исәпкә кую сәбәбе коды, Банкның идентификация коды, исәп-хисап счеты, корреспондент счеты) | |

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч |
|---|---|---|
| Узган календарь ел өчен товарлар сатудан (эшләр башкарудан, хезмәтләр күрсәтүдән) кергән керем | Мең сум | |
| Алдагы календарь ел өчен үзендә җитештерелгән товарлар (үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр ) җибәрелгән <*> | Мең сум | |
| Төп капиталга инвестицияләр<**> | Мең сум | |
| Соңгы хисап елында хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | Кеше | |
| Соңгы хисап елында хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фонды | сум | |
| Соңгы хисап кварталында хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | Кеше | |
| Соңгы хисап кварталында хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фонды | сум | |
| Алдагы календарь ел өчен бюджетка һәм бюджеттан тыш фондларга түләнгән салым һәм салым булмаган түләүләр (өстәмә бәягә салымны исәпкә алмыйча) күләме, шул исәптән: | Мең сум | |
| салым салуның гадиләштерелгән системасы | Мең сум | |
| исәпләнгән керемгә бердәм салым | Мең сум | |
| патент бәясе | Мең сум | |
| керемгә салым | Мең сум | |
| милеккә салым | Мең сум | |
| җир салымы | Мең сум | |
| транспорт салымы | Мең сум | |
| физик затлар керемнәренә салым | Мең сум | |
| җирне арендалау | Мең сум | |
| бюджеттан тыш фондларга түләүләр | Мең сум | |
| Юридик затлар өчен: устав капиталында РФ, РФ субъектлары, муниципаль берәмлекләр, чит ил юридик затлары, чит ил гражданнары, иҗтимагый һәм дини оешмалар (берләшмәләр), хәйрия һәм башка фондлар, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары булмаган юридик затлар катнашуның гомуми өлеше | % | |

<*> Алдагы календарь елда субъект тарафыннан җитештерелгән һәм факт буенча (башка

юридик һәм физик затларга) түләп җибәрелгән товарларның бәясен үз эченә ала, шул исәптән заказчы акты буенча урында тапшырылган товарларны да кертеп (сатучы хисабына акча барып ирешү-ирешмәүгә бәйсез рәвештә).

<**> Инвестицияләр объектлары булып биналар һәм корылмалар сатып алу һәм төзү, киңәйтү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан коралландыру, машиналар, транспорт чаралары, исәпләү техникасы, медицина җиһазлары, башка җайланмалар, үлчәү һәм көйләү приборлары, инструментлары, җитештерү һәм хуҗалык инвентарьлары, йорт эчендәге юллар һәм башка объектлар, җирләрне һәм төп средстволарның арендага бирелә торган объектларын яхшыртуга капитал кертүләр тора.

Барлык юллар да тутырылырга тиеш, мәгълүмат булмаган очракта, сызык куела.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________ | / ____________ / |
| [вазифа (булган очракта)] | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |

Мөһер урыны

Тәртипкә 3 номерлы кушымта
(Форма)

Икенчел чималны җыю һәм эшкәртү эшчәнлегенә бәйле җиһазлар
сатып алу, икенчел чималны җыю урыннарын (пунктларын) сатып алу
һәм (яисә) төзү һәм (яисә) төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен
түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга
**СУБСИДИЯЛӘР КҮЛӘМЕН ИСӘПЛӘҮ**

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектының тулы исеме: ________________________
________________________________________________________________________,
салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры ______________________, төп дәүләт теркәве номеры ______________________, исәпкә кую сәбәбе коды _________________________, исәп-хисап счеты номеры _________________________, банк исеме _____________________________________, банкның идентификация коды ________________________, корреспондент счеты ___________________________________.
Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы буенча оешма эшчәнлегенең төре _______________________________________________________________

| **Хезмәт, товар атамасы** | **Хезмәтләр яисә товар белән тәэмин итүче оешма исеме** | **Хезмәтнең, товарның бәясе, сум** | **Шул исәптән** | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **Субсидия акчалары хисабына, сум*** | **Үз акчалары хисабына, сум** |
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** |
| | | | | |
| Барлыгы: | | | | |

<*> - икенчел чималны җыю һәм эшкәртү эшчәнлегенә бәйле җиһазлар сатып алу буенча түләүгә субъектның документаль расланган чыгымнарының 50 проценты күләмендә, әмма 2 000 000 (Ике миллион) сумнан артык түгел;
- икенчел чималны җыю урыннарын (пунктларын) төзекләндерүгә тотылган чыгымнарның 50 проценты күләмендә, әмма 1 000 000 (Бер миллион) сумнан артык түгел.

_______________________________ ________________ /_____________________/
[җитәкче вазифасы атамасы (булган очракта)] (имза) (имзаның аңлатмасы)

Баш бухгалтер ________________ /_____________________/
(булган очракта) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Исәпләү тикшерелде 20___ елның «___» ___________

_______________________________ ________________ /_____________________/
(хезмәткәрнең вазифасы атамасы) (имза) (имзаның аңлатмасы)

20___ елның «___» ___________

Тәртипкә 4 номерлы кушымта
(Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә**
**РИЗАЛЫК**

Мин, ____________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))
__________________________________________________адресы буенча теркәлгән,
паспорт: сериясе _____________ номеры ____________________,
________ елның «______» _______________ ________________________________
(бирелү вакыты) (документ биргән орган атамасы)
___________________________________________________ тарафыннан бирелгән,
____________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъекты вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))
__________________________________________________ адресы буенча теркәлгән,
паспорт: сериясе _____________ номеры ____________________,
________ елның «______» _______________ ________________________________
(бирелү вакыты) (документ биргән орган атамасы)
___________________________________________________ тарафыннан бирелгән,
____________________________________________________________________,
[ышаныч кәгазе яки әлеге вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган башка документ реквизитлары (шәхси мәгълүматлар субъекты вәкиленнән ризалык алганда)]

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан чыгымнарның бер өлешен компенсацияләү өчен субсидия бирү турындагы килешүне төзү һәм үтәү максатыннан ________________________________ _______________________________________операторына автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шәхси мәгълүматларны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), чыгару, куллану, тапшыру (тарату, бирү, куллануга рөхсәт бирү), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, вакытлыча тыю, бетерү, юкка чыгаруны кертеп, минем шәхси мәгълүматларымны, аерым алганда (алга таба кирәклесенең астына сызарга):

1) фамилия, исем яки атасы исеме үзгәрү турындагы белешмәләрне дә кертеп, анкета мәгълүматларын, яшәү урыны адресын (теркәлү буенча һәм факттагы), электрон почта адресын һәм телефон номерын;

2) сериясен, номерын, бирелү датасын, документ биргән органның

атамасын кертеп, паспорт мәгълүматларын яки шәхесне һәм гражданлыкны таныклый торган башка документ мәгълүматларын;

3) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры турында мәгълүматларны;

4) салым органында исәпкә кую турында мәгълүматларны;

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмау турында мәгълүматларны;

6) бюджеттан тыш фондларга иминият взнослары, пенялар, штрафлар буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматларны;

7) кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетлары турында мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Шәхси мәгълүматларымны өченче як аша гына алып булган очракта, миңа, шәхси мәгълүматларны алуның максатларын, мөмкин булган чыганакларын һәм ысулларын күрсәтеп, бу хакта алдан хәбәр итэлергә һәм моның өчен шулай ук ризалык алынырга тиеш.

Миңа шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы булуым турында аңлатылды.

Ризалык аңа имза куелган көннән гамәлгә керә һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүнең максатына ирешкәнче яки язма формада ризалыкны кире алганчы, билгесез вакыт дәвамында гамәлдә була.

____________________________________________________________

(имза, фамилия һәм инициаллар)

Ризалык бирү датасы: 20___ елның «____» ____________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 29 октябрендәге
4563 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә гаризаларны сайлап алу комиссиясе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә гаризаларны сайлап алу комиссиясенең (алга таба – Комиссия) эш тәртибен билгели.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка хокукый актларына, Татарстан Республикасы хокукый актларына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан субсидияләр алуга гаризаларны сайлап алу процедурасын башкара, шул исәптән:

- Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) һәм әлеге Нигезләмә буенча субсидияләр алуга гаризаларны карап тикшерә;

- субсидия бирү турында яисә аны бирүгә гаризаларны кире кагу турында карар кабул итә.

4. Комиссия әгъзалары тарафыннан Тәртип белән билгеләнгән таләпләр нигезендә тапшырылган документлар буенча бәйсез һәм шәхсән рәвештә Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган гаризаларны карап тикшерә һәм бәяли.

5. Комиссия утырышы аңа вәкаләтле органнан гаризалар килеп ирешкән көннән соң 10 эш көне эчендә уздырыла.

6. Комиссия эшен оештыру-техника яктан тәэмин итүне Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты гамәлгә ашыра.

7. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия сәркатибе, Комиссиянең башка әгъзалары керә.

8. Комиссия рәисе:

- Комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә;

- Комиссия утырышларын җыя һәм алып бара;

- Комиссия беркетмәсен раслый һәм имзалый;

- кирәк булган очракта, Комиссия утырышын үткәрүне Комиссия рәисе урынбасарына йөкли;

- Комиссия әгъзаларына аның эшчәнлеге буенча телдән һәм язмача йөкләмәләр бирә;

- Комиссиянең тиешле эшчәнлеген оештыру өчен кирәкле башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

9. Комиссия рәисе булмаган очракта, аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары үти.

10. Комиссия сәркатибе:

- Комиссия утырышларына эш материалларын әзерләүне оештыра;

- Комиссия утырышларын уздыруны оештыруны тәэмин итә, Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышын уздыру вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

- Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;

11. Комиссия утырышлары, аларда Комиссия әгъзаларының яртысыннан артыграгы катнашкан очракта, тулы хокуклы дип санала.

12. Комиссия әгъзалары аның утырышларында шәхсән катнаша. Комиссия әгъзасы булмаган очракта, Комиссия эшендә аның вазифаларын вакытлыча башкаручы катнаша.

13. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, Комиссиянең утырышта катнашучы күпчелек әгъзалары уңай тавыш биргәндә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

14. Комиссия утырышын уздыру нәтиҗәләре буенча Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә Комиссия рәисе яисә аның утырышта рәислек иткән урынбасары тарафыннан раслана. Комиссия беркетмәсе, субсидия алучы субъектларны күрсәтеп, утырышны уздыру көненнән алып 10 эш көне эчендә вәкаләтле орган тарафыннан Казан шәһәре җирле үзидарә

органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында (www.kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/komitet-ekonomicheskogo-razvitiya/biznes-v-kazani) урнаштырыла.

______________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 29 октябрендәге
4563 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына икенчел чималны җыю һәм эшкәртү буенча эшчәнлек белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә гаризаларны сайлап алу комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Шакиров Илдар Сәетҗан улы | комиссия рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Алиев Булат Рафаил улы | Комиссия рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе |
| Лысачкина Елена Георгиевна | комиссия сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты икътисади үсеш комитетының эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү бүлеге башлыгы урынбасары |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Минһаҗева Гүзәл Рафаил кызы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты рәисе |
| Лысачкин Василий Александрович | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе |
| Хисамиев Илнар Госман улы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты рәисе урынбасары |
| Каяшова Лилия Роберт кызы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Финанс идарәсенең юридик һәм оештыру-кадрлар эше бүлеге башлыгы |
| Кашапова Лина Илдус кызы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты икътисади үсеш комитетының эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү бүлеге башлыгы |